ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $10^1$ статьясындагы 3 пунктының 3 пунктчасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), «пайларын)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активларын, цифрлы валюта» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 2004 елның 7 июнендәге 37-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 4 өлешенә (2011 елның 10 октябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 6; 2011, № 10 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 6 (I өлеш); 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2018, № 83 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш), «пайлар)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**3 статья**

«Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар

тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 37 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 3 өлешнең 3 пунктында «пайлар)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә;

б) 4 өлешнең 3 пунктында «пайлар)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә;

2) кушымтада «пайлар)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәргә.

**4 статья**

«Муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш); 2019, № 60 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), «пайлар)» сүзеннән соң «, цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

**5 статья**

Әлеге Закон 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2020 ел, 26 декабрь
№ 97-ТРЗ